**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О Комиссии при Президенте Республики Татарстан по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан

В целях организации взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан с федеральными органами исполнительной власти, их территориальными органами, органами местного самоуправления, общественными объединениями по вопросам сохранения, развития татарского языка как государственного языка Республики Татарстан и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан, включая татарский, в соответствии со статьей 94 Конституции Республики Татарстан **постановляю**:

1. Преобразовать Комиссию при Президенте Республики Татарстан по вопросам сохранения и развития татарского языка в Комиссию при Президенте Республики Татарстан по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан.

2. Утвердить Положение о Комиссии при Президенте Республики Татарстан по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан (приложение № 1), и ее состав (приложение № 2).

3. Признать утратившими силу:

Указ Президента Республики Татарстан от 6 июля 2020 года № УП-384 «О Комиссии при Президенте Республики Татарстан по вопросам сохранения и развития татарского языка»;

Указ Президента Республики Татарстан от 29 августа 2020 года № УП-554 «О внесении изменения в состав Комиссии при Президенте Республики Татарстан по вопросам сохранения и развития татарского языка»;

Указ Президента Республики Татарстан от 2 апреля 2021 года № УП-270 «О внесении изменений в состав Комиссии при Президенте Республики Татарстан по вопросам сохранения и развития татарского языка».

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
20 мая 2022 года
№ УП-356

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «20» мая 2022 года

№ УП-356

**Положение**
**о Комиссии при Президенте Республики Татарстан по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан**

1. Комиссия при Президенте Республики Татарстан по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан (далее – Комиссия), является постоянно действующим консультативным органом, созданным в целях выработки мер по обеспечению сохранения и развития татарского языка как государственного языка Республики Татарстан и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан, включая татарский.

2. Положение о Комиссии и ее состав утверждаются Указом Президента Республики Татарстан.

3. Комиссия в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

4. Основными задачами Комиссии являются:

координация деятельности органов исполнительной власти Республики Татарстан с иными органами государственной власти Республики Татарстан, организация взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан с федеральными органами исполнительной власти, их территориальными органами, органами местного самоуправления, общественными объединениями по вопросам сохранения, развития татарского языка как государственного языка Республики Татарстан и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан, включая татарский;

определение актуальных задач сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан, выработка возможных подходов к их решению;

определение приоритетных направлений научных исследований, касающихся эффективности сохранения и развития татарского языка;

изучение и обобщение лучших практик, методик и технологий обучения татарскому языку как государственному языку Республики Татарстан и родным языкам представителей народов, проживающих в Республике Татарстан, включая татарский, определение мер по их распространению;

инициирование мер программной и грантовой поддержки перспективных направлений и проектов, связанных с развитием сферы использования татарского языка как государственного языка Республики Татарстан и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан, включая татарский;

изучение особенностей сохранения и развития татарского языка за пределами территории Республики Татарстан, содействие использованию татарского литературного языка;

поддержка инициатив, творческих начинаний, направленных на сохранение татарского языка и его развитие, в том числе разработку на татарском языке уникальных продуктов, представляющих особый интерес прежде всего для молодежи;

поддержка инициатив, творческих начинаний, направленных на сохранение и развитие родных языков народов, проживающих в Республике Татарстан;

выработка предложений по совершенствованию нормативного правового регулирования в сфере языкового общения, а также участие в экспертной оценке законодательных инициатив;

выработка предложений по совершенствованию условий, способствующих привлекательности изучения родных языков, в том числе по развитию информационно-коммуникативных технологий, повышающих эффективность освоения татарского языка, а также популяризации разработок, способствующих повышению качества изучения родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан;

рассмотрение предложений по развитию билингвального и полилингвального образования;

развитие поликультурного аспекта татарского языка как значимого средства продвижения татарской культуры в мировом пространстве и приобщения татар к богатейшим достижениям мировой культуры;

развитие речевой культуры и татарского литературного языка, а также содействие сохранению речевой культуры и литературного языка других народов, представители которых проживают в Республике Татарстан;

совершенствование подготовки переводчиков, педагогов, деятелей культуры, научных кадров, специалистов, деятельность которых связана с профессиональным использованием татарского языка и других языков народов, проживающих в Республике Татарстан;

совершенствование издательской деятельности на татарском языке и повышение привлекательности ее продуктов;

содействие обеспечению доступности издательской продукции на родных языках народов, проживающих в Республике Татарстан;

содействие популяризации знаний о родных языках народов, проживающих в Республике Татарстан.

5. Комиссия для решения возложенных на нее задач имеет право:

запрашивать в установленном законодательством порядке от органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан (далее – территориальные органы федеральных органов исполнительной власти), иных государственных органов, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления), а также общественных объединений, научных и иных организаций материалы и информацию по вопросам, относящимся к компетенции Комиссии;

приглашать на свои заседания представителей органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, иных государственных органов, органов местного самоуправления, а также общественных объединений, научных и иных организаций;

вносить в установленном порядке в органы государственной власти Республики Татарстан, территориальные органы федеральных органов исполнительной власти, иные государственные органы, органы местного самоуправления предложения по вопросам, относящимся к компетенции Комиссии;

создавать при необходимости рабочие и экспертные группы из числа ученых и специалистов для подготовки предложений по решению вопросов сохранения, развития татарского языка как государственного языка Республики Татарстан и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан, включая татарский.

6. Состав Комиссии формируется из представителей органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, иных государственных органов, органов местного самоуправления, а также общественных объединений, научных и иных организаций. В состав Комиссии при необходимости могут включаться иные лица.

7. В состав Комиссии входят председатель, заместитель председателя, секретарь и члены Комиссии, осуществляющие свою деятельность на общественных началах.

8. Руководит работой Комиссии и проводит ее заседания председатель Комиссии, а в его отсутствие – заместитель председателя Комиссии.

9. Секретарь Комиссии:

готовит проект плана работы Комиссии, формирует повестку дня заседания Комиссии с учетом предложений членов Комиссии;

осуществляет информирование членов Комиссии и иных заинтересованных лиц о месте, времени проведения и повестке дня заседания Комиссии, обеспечивает их необходимыми материалами;

организует работу по подготовке заседаний Комиссии;

ведет протоколы заседаний Комиссии;

осуществляет контроль за выполнением решений Комиссии.

В случае отсутствия секретаря его обязанности по решению председателя Комиссии возлагаются на одного из членов Комиссии.

10. Комиссия осуществляет свою деятельность в соответствии с планом работы, утверждаемым председателем Комиссии.

Члены Комиссии вносят предложения по плану работы, повестке дня заседания и участвуют в подготовке материалов к заседанию Комиссии.

11. Заседания Комиссии проводятся по мере необходимости, но не реже двух раз в год.

12. Заседание Комиссии считается правомочным, если в нем принимают участие более половины ее членов.

13. В случае отсутствия члена Комиссии на заседании он имеет право изложить в письменной форме свое мнение по рассматриваемым вопросам, которое подлежит обязательному приобщению к протоколу заседания Комиссии.

14. Решения Комиссии принимаются простым большинством голосов. При равенстве голосов членов Комиссии голос председательствующего на заседании является решающим.

15. Решение Комиссии оформляется протоколом, который подписывается секретарем Комиссии и утверждается председательствующим на заседании Комиссии.

16. Организационное и информационное обеспечение деятельности Комиссии осуществляется Аппаратом Президента Республики Татарстан совместно с Аппаратом Государственного Совета Республики Татарстан.

---

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «20» мая 2022 года

№ УП-356

**Состав**
**Комиссии при Президенте Республики Татарстан по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан**

| | |
|---|---|
| Ахметов<br>Марат Готович | заместитель Председателя Государственного Совета Республики Татарстан, председатель Комиссии (по согласованию) |
| Хадиуллин<br>Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан, заместитель председателя Комиссии |
| Гарипова<br>Чулпан Шафигулловна | заведующий отделом по обеспечению деятельности Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по образованию, культуре, науке и национальным вопросам, секретарь Комиссии (по согласованию) |
| Агапов<br>Олег Дмитриевич | советник ректора по стратегическим инициативам, профессор кафедры развития институтов гражданского общества частного образовательного учреждения высшего образования «Казанский инновационный университет имени В.Г. Тимирясова (ИЭУП)» (по согласованию) |
| Аминов<br>Ильшат Юнусович | генеральный директор акционерного общества «Телерадиокомпания «Новый Век» (по согласованию) |
| Ахметзянова<br>Лилия Марсовна | начальник Управления национального образования Министерства образования и науки Республики Татарстан |
| Аюпова<br>Ирада Хафизяновна | министр культуры Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Белоусова Людмила Даниловна | директор государственного бюджетного учреждения «Культурный центр имени Я.Е. Емельянова», руководитель Исполнительного комитета общественной организации кряшен Республики Татарстан (по согласованию) |
| Валеев Разиль Исмагилович | народный поэт Республики Татарстан, лауреат Государственной премии Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая (по согласованию) |
| Габдрахманова Гульнара Закариевна | председатель Государственного комитета Республики Татарстан по архивному делу |
| Галиуллин Рустем Гусманович | руководитель, главный редактор филиала акционерного общества «ТАТМЕДИА» «Редакция журнала «Казан утлары» (по согласованию) |
| Гарипов Ильнур Махмутович | первый заместитель Руководителя Аппарата Президента Республики Татарстан – начальник Управления по работе с территориями Президента Республики Татарстан |
| Гильмутдинов Ильдар Ирекович | первый заместитель председателя Комитета Государственной Думы Федерального Собрания Российской Федерации по делам национальностей (по согласованию) |
| Гилязов Искандер Аязович | директор Института татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук Республики Татарстан (по согласованию) |
| Губайдуллин Экзам Саматович | председатель Ассоциации «Совет муниципальных образований Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Загидуллина Дания Фатиховна | вице-президент Академии наук Республики Татарстан (по согласованию) |
| Зайдуллин Ркаил Рафаилович | депутат Государственного Совета Республики Татарстан, председатель общественной организации «Союз писателей Республики Татарстан» (Творческий союз) (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Замалетдинов Радиф Рифкатович | директор Института филологии и межкультурной коммуникации федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет» (по согласованию) |
| Зарипов Айрат Ринатович | председатель Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по образованию, культуре, науке и национальным вопросам (по согласованию) |
| Иванова Раиса Михайловна | учитель родного мордовского (эрзянского) языка и литературы муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения основной общеобразовательной школы № 8 Бугульминского муниципального района Республики Татарстан (по согласованию) |
| Лучшева Людмила Владимировна | доцент кафедры социальной работы, педагогики и психологии федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский национальный исследовательский технологический университет», член правления местной общественной организации «Казанское русское национально-культурное объединение» (по согласованию) |
| Миннуллин Ким Мугаллимович | директор Института языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан (по согласованию) |
| Мусихина Людмила Ивановна | заместитель председателя Совета региональной общественной организации «Национально-культурная автономия марийцев Республики Татарстан», председатель местной общественной организации «Национально-культурная автономия марийцев города Казани» (по согласованию) |
| Мустафин Данил Махмутович | начальник Управления по реализации национальной политики Департамента Президента Республики Татарстан по вопросам внутренней политики |
| Низамова Ляйсан Гаптелхановна | начальник Управления культуры и развития языков народов Республики Татарстан Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Нугаев<br>Камиль Асгатович | заместитель председателя Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по бюджету, налогам и финансам (по согласованию) |
| Нурмиев<br>Сайдаш Талгатович | директор муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Ципьинская средняя общеобразовательная школа» Балтасинского муниципального района Республики Татарстан (с изучением марийского и удмуртского языков) (по согласованию) |
| Поселкина<br>Марина Николаевна | директор муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Киртелинская средняя общеобразовательная школа» Тетюшского муниципального района Республики Татарстан (с изучением мордовского языка) (по согласованию) |
| Сагдатшин<br>Ильдар Камилевич | генеральный директор государственного унитарного предприятия Республики Татарстан «Татарское книжное издательство» (по согласованию) |
| Сагитова<br>Гузель Рамзилевна | заместитель руководителя Исполнительного комитета муниципального образования города Казани (по согласованию) |
| Салимгараев<br>Айдар Саитгараевич | руководитель Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» |
| Самигуллин<br>Камиль хазрат<br>(Самигуллин<br>Камиль Искандерович) | председатель Духовного управления мусульман Республики Татарстан, муфтий (по согласованию) |
| Семенов<br>Виталий Геннадьевич | директор муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Ошторма-Юмьинская средняя школа» Кукморского муниципального района Республики Татарстан, председатель местной общественной организации «Национально-культурная автономия удмуртов Кукморского муниципального района Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Сулейманов<br>Тимур Джавдетович | министр по делам молодежи Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Тухватуллин Рамиль Чингизович | депутат Государственного Совета Республики Татарстан, артист драмы государственного бюджетного учреждения «Татарский государственный Академический театр имени Галиасгара Камала» (по согласованию) |
| Федоров Генадий Зиновьевич | директор муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Чувашскомайнская основная общеобразовательная школа» Алексеевского муниципального района Республики Татарстан (с изучением чувашского языка) (по согласованию) |
| Халимов Рамиль Марванович | заместитель руководителя Исполнительного комитета муниципального образования «город Набережные Челны» (по согласованию) |
| Хамидуллина Камария Зиннуровна | педагог дополнительного образования муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Татарская гимназия № 2 имени Шигабутдина Марджани при Казанском федеральном университете» Московского района г. Казани (по согласованию) |
| Хасанов Гали Ахтарович | председатель региональной общественной организации «Национально-культурная автономия башкир – Курултай (конгресс) башкир Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Хашимова Нурия Миннахматовна | исполнительный директор Фонда поддержки развития культуры при Президенте Республики Татарстан |
| Хухунашвили Маринэ Мануиловна | директор муниципального бюджетного учреждения дополнительного образования Центра образования «Многонациональная воскресная школа» Вахитовского района г. Казани, председатель правления местной общественной организации «Национально-культурная автономия грузин г. Казани «Сиони» (по согласованию) |
| Шайдуллина Нурсюя Нурулловна | помощник Государственного Советника Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Шакиров Данис Фанисович | руководитель Исполнительного комитета Всемирного конгресса татар (по согласованию) |
| Шамсутдинов Айдар Ильдарович | директор государственного автономного общеобразовательного учреждения «Полилингвальный комплекс «Адымнар – путь к знаниям и согласию» г. Казани (по согласованию) |
| Шафигуллин Лутфулла Нурисламович | председатель Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по экономике, инвестициям и предпринимательству (по согласованию) |
| Яковлев Константин Геннадиевич | заместитель председателя Совета региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан» – руководитель Исполнительного комитета Совета региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан» (по согласованию) |

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе турында**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр белән Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен, татар телен дә кертеп, саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлеген оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясен Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе итеп үзгәртеп корырга.

2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе турында» 2020 елның 6 июлендәге ПУ-384 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе составына үзгәреш кертү турында» 2020 елның 29 августындагы ПУ-554 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 2 апрелендәге ПУ-270 номерлы Указы.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 20 май
№ ПУ-356

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 20 » маендагы
ПУ- 356 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен, татар телен дә кертеп, саклау һәм үстерүне тәэмин итү чараларын эшләү максатларында төзелгән даими эшләүче консультация органы булып тора.

2. Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә раслана.

3. Комиссия Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасының законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.

4. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Татарстан Республикасының башка дәүләт хакимияте органнары белән эшчәнлеген килештерү, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр белән Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен, татар телен дә кертеп, саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеген оештыру;

татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерүнең актуаль мәсьәләләрен билгеләү һәм аларны хәл итүнең мөмкин булган ысулларын эшләү;

татар телен саклау һәм үстерүнең нәтиҗәлелеген тәэмин итүгә юнәлтелгән фәнни тикшеренүләрнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү;

Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен,

татар телен дә кертеп, укыту эшендәге иң яхшы тәҗрибәләрне, методикаларны һәм технологияләрне өйрәнү һәм гомумиләштерү һәм аларны тарату чараларын билгеләү;

Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак татар теленең һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләренең, татар телен дә кертеп, кулланылыш даирәсен киңәйтү белән бәйле перспективалы юнәлешләргә һәм проектларга программалар һәм грантлар аша ярдәм күрсәтү башлангычлары белән чыгу;

Татарстан Республикасы территориясеннән читтә татар телен саклау һәм үстерү белән бәйле үзенчәлекләрне өйрәнү, татар әдәби телен куллану даирәсен киңәйтүдә ярдәм итү;

татар телен саклауга һәм аны үстерүгә юнәлтелгән эшчәнлеккә, иҗади башлангычларга, шул исәптән, беренче чиратта яшьләр өчен аеруча кызыксыну тудырачак уникаль продуктларны татар телендә эшләүгә булышлык итү;

Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлтелгән эшчәнлеккә, иҗади башлангычларга булышлык итү;

тел ярдәмендә аралашу өлкәсендә норматив хокукый җайга салу эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү, шулай ук законнар чыгару башлангычларына экспертлар бәяләмәсе әзерләүдә катнашу;

туган телләрне өйрәнүгә кызыксындыруны арттыруга ярдәм итәчәк шартларны камилләштерү, шул исәптән татар телендә аралашуның нәтиҗәлелеген арттыруга этәргеч бирә торган мәгълүмати-коммуникатив технологияләрне үстерү буенча тәкъдимнәр эшләү, шулай ук Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен өйрәнүнең сыйфатын яхшыртуга ярдәм итү алымнарын популярлаштыру;

билингваль һәм полилингваль белем бирүне үстерү буенча тәкъдимнәрне карап тикшерү;

татар мәдәниятен дөньякүләм дәрәҗәдә танытуның һәм татар халкын дөнья мәдәниятенең бай казанышлары белән таныштыруның мөһим чарасы буларак татар теленең күпмәдәниятлелек аспектын үстерү;

татар телендә аралашу культурасын һәм татар әдәби телен үстерү, шулай ук Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрендә аралашу культурасын һәм әдәби телләрен саклауга булышлык итү;

татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен һөнәри куллану белән бәйле эшчәнлек алып баручы тәрҗемәчеләр, укытучылар, мәдәният эшлеклеләре, фәнни кадрлар, белгечләр әзерләү эшен камилләштерү;

татар телендә нәшрият эшчәнлеген камилләштерү һәм аның продуктлары белән кызыксынуны арттыру;

Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрендә нәшер ителгән продукцияне сатып алу мөмкинлеген тәэмин итүгә булышлык күрсәтү;

Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләре турында белемнәрне популярлаштыруга булышлык итү.

5. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итүдә түбәндәгеләргә хокуклы:

законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан (алга таба – федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары), башка дәүләт органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарыннан (алга таба – җирле үзидарә органнары), шулай ук җәмәгать берләшмәләреннән, фәнни һәм башка оешмалардан Комиссия компетенцияләренә караган мәсьәләләр буенча материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук җәмәгать берләшмәләре, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләрен үз утырышларына чакырырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә;

ихтыяҗ туганда, Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен, татар телен дә кертеп, саклау һәм үстерү мәсьәләләрен хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү өчен галимнәр һәм белгечләрдән торган эш һәм эксперт төркемнәре төзергә.

6. Комиссия составы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук җәмәгать берләшмәләре, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләреннән формалаштырыла. Комиссия составына, кирәк булган очракта, башка затлар да кертелергә мөмкин.

7. Комиссия составына рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм Комиссия әгъзалары керә, алар үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында алып бара.

8. Комиссия эшенә Комиссия рәисе, ул булмаганда – Комиссия рәисе урынбасары җитәкчелек итә һәм аның утырышларын алып бара.

9. Комиссия секретаре:

Комиссиянең эш планы проектын әзерли, Комиссия әгъзалары тәкъдимнәрен исәпкә алып, Комиссия утырышының көн тәртибен төзи;

Комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга Комиссия утырышы булачак урын, аны уздыру вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

Комиссия утырышларын әзерләү буенча эшне оештыра;

Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара;

Комиссия карарларының үтәлешен контрольдә тота.

Секретарь булмаганда, аның вазыйфалары Комиссия рәисе карары нигезендә Комиссия әгъзаларының берсенә йөкләнә.

10. Комиссия үз эшчәнлеген Комиссия рәисе тарафыннан расланган эш планы нигезендә алып бара.

Комиссия әгъзалары утырышның эш планына, көн тәртибенә кагылышлы тәкъдимнәр кертә һәм Комиссия утырышына материаллар әзерләүдә катнаша.

11. Комиссия утырышлары ихтыяҗ туган саен, ләкин ким дигәндә елына ике тапкыр үткәрелә.

12. Комиссия әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашкан очракта, Комиссия утырышы гамәлгә хокуклы дип санала.

13. Утырышта катнашмаган очракта, Комиссия әгъзасы карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язмача белдерергә хокуклы һәм ул мәҗбүри рәвештә утырыш беркетмәсенә теркәлергә тиеш.

14. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары саны тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

15. Комиссия карары Комиссия секретаре кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан раслана.

16. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм мәгълүмати тәэмин итү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты белән берлектә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты тарафыннан тормышка ашырыла.

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 20 » маендагы
ПУ- 356 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы**
**Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Әхмәтов<br>Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Комиссия рәисе (килешү буенча) |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, Комиссия рәисе урынбасары |
| Гарипова<br>Чулпан Шәфигулла кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире, Комиссия секретаре (килешү буенча) |
| Агапов<br>Олег Дмитриевич | «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесе ректорының стратегик башлангычлар буенча киңәшчесе, граждан җәмгыяте институтларын үстерү кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| Әминов<br>Илшат Юныс улы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Әхмәтҗанова<br>Лилия Марс кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Милли мәгариф идарәсе башлыгы |
| Әюпова<br>Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |

| | |
|---|---|
| Белоусова<br>Людмила Даниловна | «Я.Е. Емельянов исемендәге мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, Татарстан Республикасының керәшен иҗтимагый оешмасы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Вәлиев<br>Разил Исмәгыйль улы | Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (килешү буенча) |
| Габдрахманова<br>Гөлнара Зәкәрия кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Галиуллин<br>Рөстәм Госман улы | «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыятенең «Казан утлары» журналы редакциясе» филиалы җитәкчесе, баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Гарипов<br>Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| Гыйльметдинов<br>Илдар Ирек улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Милләтләр эшләре комитеты рәисенең беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Гыйләҗев<br>Искәндәр Аяз улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин<br>Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Заһидуллина<br>Дания Фатыйх кызы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Зәйдуллин Ркаил Рафаил улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) рәисе (килешү буенча) |
| Җамалетдинов Рәдиф Рифкать улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры (килешү буенча) |
| Зарипов Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Иванова Раиса Михайловна | Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының 8 номерлы төп гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган мордва (эрзя) теле һәм әдәбияты укытучысы (килешү буенча) |
| Лучшева Людмила Владимировна | «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең социаль эш, педагогика һәм психология кафедрасы доценты, «Казанның Рус милли-мәдәни берләшмәсе» җирле иҗтимагый оешмасы идарәсе әгъзасы (килешү буенча) |
| Миңнуллин Ким Мөгаллим улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры (килешү буенча) |
| Мусихина Людмила Ивановна | «Татарстан Республикасының мари милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы рәисе урынбасары, «Казан шәһәренең мари милли-мәдәни мохтарияте» җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Мостафин<br>Данил Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы |
| Низамова<br>Ләйсән Габделхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Нугаев<br>Камил Әсгать улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Нурмиев<br>Сәйдәш Тәлгать улы | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Чепья урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (мари һәм удмурт телләре өйрәнелә торган) директоры (килешү буенча) |
| Поселкина<br>Марина Николаевна | Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Киртәле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (мордва теле өйрәнелә торган) директоры (килешү буенча) |
| Сәгъдәтшин<br>Илдар Камил улы | Татарстан Республикасының «Татарстан китап нәшрияты» дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры (килешү буенча) |
| Сәгыйтова<br>Гүзәл Рәмзил кызы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сәмигуллин<br>Камил хәзрәт<br>(Сәмигуллин<br>Камил Искәндәр улы) | Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Семенов<br>Виталий Геннадьевич | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Оштырма-Юмья урта мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының удмурт милли-мәдәни мохтарияте» җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Сөләйманов<br>Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Төхвәтуллин<br>Рамил Чыңгыз улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты (килешү буенча) |
| Федоров<br>Генадий Зиновьевич | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Чуаш Майнасы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (чуваш теле өйрәнелә торган) директоры (килешү буенча) |
| Хәлимов<br>Рамил Мәрван улы | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Хәмидуллина<br>Камәрия Зиннур кызы | Казан шәһәре Мәскәү районының «Казан федераль университеты каршындагы Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 номерлы татар гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең өстәмә белем бирү укытучысы (килешү буенча) |
| Хәсәнов<br>Гали Әхтәр улы | «Татарстан Республикасы башкорт милли-мәдәни мохтарияте – башкортлар корылтае (конгрессы)» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Һашимова<br>Нурия Миңнәхмәт кызы | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм итү фонды башкарма директоры |

| | |
|---|---|
| Хухунашвили<br>Маринэ Мануиловна | Казан шәһәре Вахитов районының «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» мәгариф үзәге муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры, Казан шәһәренең «Сиони» грузин милли-мәдәни мохтарияте» җирле иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Шәйдуллина<br>Нурсөя Нурулла кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе ярдәмчесе |
| Шакиров<br>Данис Фәнис улы | Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шәмсетдинов<br>Айдар Илдар улы | Казан шәһәренең «Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл» күптелле белем бирү комплексы» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Шәфигуллин<br>Лотфулла Нурислам улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Яковлев<br>Константин Геннадиевич | «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы рәисе урынбасары – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |